**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

29.06.2024

№ 218

**2024–2025 еллар чорына алар тарафыннан электр энергиясен куллану режимын чикләү икътисадый, экологик, социаль нәтиҗәләргә китерүе мөмкин булган электр энергиясен (куәтен) кулланучылар исемлеген раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы боерыгы белән расланган Электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү кагыйдәләренең 15, $15^1$ пунктлары нигезендә:

1. 2024–2025 еллар чорына алар тарафыннан электр энергиясен куллану режимын чикләү икътисадый, экологик, социаль нәтиҗәләргә китерүе мөмкин булган электр энергиясен (куәтен) кулланучыларның кушымтада бирелгән исемлеген расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Рәисенең «2023–2024 еллар чорына алар тарафыннан электр энергиясен куллану режимын чикләү икътисадый, экологик, социаль нәтиҗәләргә китерүе мөмкин булган электр энергиясен (куәтен) кулланучылар исемлеген раслау турында» 2023 елның 30 июнендәге 218 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Рәисенең «2023–2024 еллар чорына алар тарафыннан электр энергиясен куллану режимын чикләү икътисадый, экологик, социаль нәтиҗәләргә китерүе мөмкин булган электр энергиясен (куәтен) кулланучылар исемлегенә үзгәреш кертү турында» 2023 елның 5 декабрендәге 368 номерлы боерыгы.

**Татарстан Республикасы Рәисе** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН